*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________** **Шифр _____________**

(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2017-2018 учебный год**
**11 класс**

**I. Б графасындагы рус теле сүзләренә А графасындагы татар сүзләренең цифрларын куеп тәңгәлләштерегез.** / Напишите в графу Б рядом с русскими словами цифры, соответствующие цифрам татарских слов из графы А (10 баллов).

| А | | Б | |
|---|---|---|---|
| 1 | кадак | | ёжик /ёж |
| 2 | керпе | | душица |
| 3 | толым | | змея |
| 4 | мәтрүшкә | | горячий |
| 5 | кайтаваз | | гвоздь |
| 6 | утын | | детство |
| 7 | балачак | | остаток |
| 8 | елан | | эхо |
| 9 | калдык | | коса |
| 10 | кайнар | | дрова |

**II. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз /** Вместо многоточий вставьте нужные буквы (5 баллов).

Та...га таба җил басыла төште. Озак та үтмәде, күбәләк-күбәләк кар ява башлады.

...аваның бу үзгәреше безне и...рат шатландырды. Без, өч тә...лек буенча дошман тылында йөреп, өст...безгә йөкләнгән бурычны үтәгәннән соң, үз подразделениеб...зг... кайтып килә идек. Артта ап-ак тасма шикелле ча...гы эзләре сузылып кала. Менә шул эзләр күңелне борч...й. Алардан ...ичкая качып булмый. (*Г. Әпсәләмов буенча)*

**III. Бирелгән тексттан ясалма сүзләрне язып алыгыз. /** Выпишите из текста производные слова. (10 баллов)

...Икенче атна инде, Гасыйм өч бүлмәле квартирында ялгыз яши. Хатыны больницада, улы Кырымга китте. Төрлесен уйларга туры килә аңа ялгызлыкта. Аеруча бүгенге кебек йөрәгенең хәлсезлеген ачык сизеп торган чакта; ул бит бала түгел, үз хәленең җитдилеген аңлый торган кеше. *(Ә. Еники буенча)*

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**IV. Күп нокталар урынына нинди тыныш билгеләре куела?/** Напишите, какие знаки препинания ставятся в предложении. (10 баллов)

Бик табигый 1)<...> Әсфан институт бетереп, армиягә 2) <...> действительный хезмәткә киткәч 3)<...> буш кесә белән кайтачак бу солдатны ике ел буена көтәргә сабырлыклары җитмәде 4)<...> беришесе кияү тапты 5)<...> аеруча җитезләре кияүдән кире әйләнеп кайтырга да өлгерделәр (Ф.Хөсни).

**1)____________________________________________**
**2)____________________________________________**
**3)____________________________________________**

**4)________________________________________**
**5)________________________________________**

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)




**Горизонталь буенча:**
1. Мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән яки якын торган сүзләр. 5. Исемне ачыклап килә торган сүз төркеме. 6. Төшенчә һәм предметларны төгәл атый торган конкрет бер мәгънәле сүз яисә сүзтезмә. 9. Зат яки предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен, торышын белдерә торган сүзләр. 10. Җөмләдә баш килеш мәгънәсендәге сүз белән бирелеп, бер җөмлә кисәгенә дә буйсынмыйча, хәбәр белән генә бәйләнеп килгән кисәк. 11. Кешенең эчке кичерешләрен, хисләрен, тойгыларын һәм ихтыярын белдергән сүзләр. 12. Телдәге авазларның бер төре. 14. Сүзләрне төзү өчен хезмәт иткән, бүленми торган иң кечкенә аваз берәмлеге.

**Вертикаль буенча:**
2. Сөйләмдә тавышның хәрәкәте. 3. Мәгънәләре буенча капма-каршы сүзләр. 4. Сүзнең килеп чыгышын һәм мәгънә үсешен өйрәнә торган фән. 7. Предмет һәм затларны белдерә торган сүз төркеме. 8. Исем белән белдерелгән теләсә нинди җөмлә кисәген ачыклаган иярчен кисәк. 10. Телдәге авазларның бер төре. 13. Исем, сыйфат, рәвеш, сан кебек сүз төркемнәрен алмаштырып килә ала торган сүз төркеме. 15. Әйбернең санын, исәбен, микъдарын белдерә торган сүзләр.

**VI. Муса Җәлил шигыреннән өзек килеп чыгарлык итеп, калын хәреф белән бирелгән сүзләрне җәя эчендә соралган рәвештә төрләндерегез һәм бер-берсенә бәйләгез, аска язып куегыз** /Воспользуясь подсказками в скобках, склоняйте и свяжите выделенные слова таким образом, чтобы в итоге получилось четверостишие из стихотворения Мусы Джалиля, запишите ниже. (15 баллов).

1 юл. **Мин-** (*зат алмашлыгы, 1 зат, берлек санда, баш килештә*), **кабыз-** (*фигыль, хикәя фигыль, билгеле үткән заман, 1 зат берлектә*), **җыр-** (*исем, берлек санда, тартымсыз, урын-вакыт килешендә*), **ялкын-** (*исем, берлек санда, тартымсыз, баш килештә*), **ит**- (ярдәмче фигыль, 1 төр хәл фигыль);

2 юл. **Йөрәк**- (*исем, берлек санда, баш килештә, 1 зат тартым белән төрләнгән*), **һәм** (*җыючы теркәгеч*), **хак-** (*ясалма исем, җыелма күплек кушымчасы алган, тартымсыз, баш

*килештә*), **куш-** (*фигыль, исемләшкән үткән заман сыйфат фигыль, берлектә, төшем килеше кушымчасын алган*);

3 юл. **Җыр-** (*исем, 1 зат берлектәге тартым белән төрләнгән, баш килештә*), **белән** (*бәйлек*), **дус-** (*исем, берлек санда, тартымсыз, төшем килешендә*), **иркә-** (*ясалма фигыль, билгеле үткән заман хикәя фигыль, 1 зат берлектә*);

4 юл. **Җыр-** (*исем, 1 зат берлектәге тартым белән төрләнгән, баш килештә*), **белән-** (*бәйлек*), **җиң-** (*фигыль, билгеле үткән заман хикәя фигыль, 1 зат берлектә*), **дошман-** (*исем, берлек санда, тартымсыз, төшем килешендә*)

**VII. Татар телендә сүз басымы куелу үзенчәлекләре турында языгыз** / Напишите об особенностях постановки ударения в словах (15 баллов).

***Исправления не допускаются***

**VIII. Татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйри турында** *"Берәү чит телне өйрәнәсе булса, башта үз телен яхшы белсен (К. Насыйри)"* **дигән темага 80 сүздән ким булмаган инша язьгыз.** /Напишите сочинение (не менее из 80 слов) на тему *"Прежде чем учить иной язык, учи родной (К. Насыри)"* о великом татарском просветителе Каюм Насыри (20 баллов)

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________** **Шифр _____________**

(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур (ответы)**
**2017-2018 учебный год**
**11 класс**

**I. Б графасындагы рус теле сүзләренә А графасындагы татар сүзләренең цифрларын куеп тәңгәлләштерегез.** / Напишите в графу Б цифры, соответствующие цифрам татарских слов из графы А (**10 баллов. За каждое правильное соответствие по 1 баллу).**

| А | | Б | |
|---|---|---|---|
| 1 | кадак | 2 | ёж/ ёжик |
| 2 | керпе | 4 | душица |
| 3 | толым | 8 | змея |
| 4 | мәтрүшкә | 10 | горячий |
| 5 | кайтаваз | 1 | гвоздь |
| 6 | утын | 7 | детство |
| 7 | балачак | 9 | остаток |
| 8 | елан | 5 | эхо |
| 9 | калдык | 3 | коса |
| 10 | кайнар | 6 | дрова |

**II. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз /** Вместо многоточий вставьте нужные буквы (*5 баллов. За каждую правильно повтавленную букву по 0,5* б ).

ТаҢга таба җил басыла төште. Озак та үтмәде, күбәләк-күбәләк кар ява башлады.

Һаваның бу үзгәреше безне иФрат шатландырды. Без, өч тәҮлек буенча дошман тылында йөреп, өстЕбезгә йөкләНгән бурычны үтәгәннән соң, үз подразделениебЕзгӘ кайтып килә идек. Артта ап-ак тасма шикелле чаҢгы эзләре сузылып кала. Менә шул эзләр күңелне борчЫй. Алардан Һичкая качып булмый. (*Г. Әпсәләмов буенча)*

**Җавап** (*<u>Дөрес билгеләнгән һәр хәреф - 0,5 б.)</u>*: ТаҢга Һаваның иФрат тәҮлек өстЕбезгә йөкләНгән подразделениебЕзгӘ чаҢгы борчЫй Һичкая

**III. Бирелгән тексттан ясалма сүзләрне язып алыгыз. /** Выпишите из текста производные слова. (10 баллов. За каждый верный ответ по 1 баллу)

...Икенче атна инде, Гасыйм өч бүлмәле квартирында ялгыз яши. Хатыны больницада, улы Кырымга китте. Төрлесен уйларга туры килә аңа ялгызлыкта. Аеруча бүгенге кебек йөрәгенең хәлсезлеген ачык сизеп торган чакта; ул бит бала түгел, үз хәленең җитдилеген аңлый торган кеше. *(Ә. Еники буенча)*

**Җавап***<u>(табылган һәр сүз - 1 б.)</u>*: бүлмәле, төрлесен, уйларга, ялгызлыкта, аеруча, бүгенге, хәлсезлеген, ачык, җитдилеген, аңлый.

**IV. Күп нокталар урынына нинди тыныш билгеләре куела? /** Напишите, какие знаки препинания ставятся вместо многоточий в предложении. (10 баллов. *За каждый правильный знак по 2 балла.*)

Бик табигый 1)<...> Әсфан институт бетереп, армиягә 2) <...> действительный хезмәткә киткәч 3)<...> буш кесә белән кайтачак бу солдатны ике ел буена көтәргә сабырлыклары җитмәде 4)<...> беришесе кияү тапты 5)<...> аеруча җитезләре кияүдән кире әйләнеп кайтырга да өлгерделәр (Ф.Хөсни).

**Җавап** (дөрес билгеләнгән һәр очрак - 2 б.):

1) ике нокта
2) сызык
3) өтер
4) өтер
5) өтер

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов. За каждый верный ответ по 1 баллу).




**VI. Муса Җәлил шигыреннән өзек килеп чыгарлык итеп, калын хәреф белән бирелгән сүзләрне җәя эчендә соралган рәвештә төрләндерегез һәм бер-берсенә бәйләгез, аска язып куегыз** /Воспользуясь подсказками в скобках, склоняйте и свяжите выделенные слова таким образом, чтобы в итоге получилось четверостишие из стихотворения Мусы Джалиля, запишите ниже. (15 баллов. *За каждое верное слово по 1 баллу. Повтор слов в сумму баллов не входит. ).*

**Җавап** (һәр сүзгә - 1 б., кабатланган сүзләр исәпләнми):
Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны (М. Җәлил).

**VII. Татар телендә сүз басымы куелу үзенчәлекләре турында языгыз** / Напишите об особенностях постановки ударения в словах (15 баллов. *5 балла - за краткий верный ответ, 10 баллов – за верное обоснование (за каждый элемент).*).

Сүз басымы − сүздәге бер иҗекнең башкаларыннан аерылып торуы. Басым ижек составындагы сузык авазга төшә. Төрки телләрдә, аерым алганда татар телендә, басым соңгы иҗеккә омтыла, сүзгә кушымчалар ялганганда да, басым ахыргы иҗеккә күчә бара: урман - урман-чы, урман-чы-лык. Ләкин бу кагыйдәдән чыгармалар да бар:
− икенче зат боерык фигыльләрдә басым беренче иҗеккә төшә: языгыз, утырыгыз;
− исемдә хәбәрлек кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: мин укучымын, сез бәхетлесез;
− фигыльдә кайбер зат-сан кушымчалары басымны үзләренә алмыйлар: язгансың, килермен;

− фигыльдә юклык кушымчасы басымны алмый һәм үзеннән уткәрми: баргансың - бармагансың;
− рәвеш ясагыч -дай/ -дәй, -тай/ -тәй, -ча/ -чә кушымчаларына басым төшми: бүредәй, татарча;
− сорау, билгеләү, юклык алмашлыкларында, өлешчә күрсәтү һәм билгесезлек алмашлыкларында басым беренче иҗеккә тешә: кайда, барлык, һичкем;
− кайбер гарәп-фарсы алынмаларында басым алдагы иҗеккә төшә: әлбәттә, ләкин, һәммә;
− китап теле, язма тел аша кергән рус алынмаларында басым саклана: республика, опера, демократия.
Шулай да аларга кушымчалар ялганганда, ике төрле үзгәреш була:
− басым соңгы иҗектә булса, ул кушымчаларга күчә бара: диктант, диктантлар, диктантларга;
− әгәр басым алдагы иҗектә булса, ул, гадәттә, урынында кала: аренда, арендачы, арендаларга.

**VIII. Татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйри турында** *"Берәү чит телне өйрәнәсе булса, башта үз телен яхшы белсен (К. Насыйри)"* **дигән темага 80 сүздән ким булмаган инша язызыз.** /Напишите сочинение (не менее из 80 слов) на тему *"Прежде чем учить иной язык, учи родной (К. Насыри)"* о великом татарском просветителе Каюм Насыри (20 баллов)

___

___

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |